| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА ТЮРНЯСЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН ЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ТӨРНӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

Төрнәс авылы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Төрнәс авыл җирлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 14 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Кызыл Армия урамы буенча 25нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Көнчыгыш, Юл буе, Кызыл Армия, Кутузов, Суворов, Ворошилов, Көнбатыш, Совет, Көнбатыш тыкрыгы, Совет тыкрыгындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2019 елның 14 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Үзәк урам буенча 51нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Үзәк урамы, Елга Арьягы урамы, Күл урамы, Бакча урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2019 елның 21 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Яшьләр урамы буенча 6нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Яшьләр, Кыр урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 4. 2019 елның 21 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Мәктәп урамы буенча 61нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Мәктәп, Завод, Мәктәп тыкрыгы урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Төрнәс авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 500 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- Төрнәс авылы торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын сезонлы карап тоту (кардан чистарту);

- Төрнәс авылы урам утларын ремонтлау (урам утларының диод яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру);

- Төрнәс авылында су белән тәэмин итүне норматив хәлгә китерү(килешү буенча эш өчен түләү)

- Төрнәс авылында иске агачларны җыештыру (килешү буенча эш өчен түләү)

- Төрнәс авылы торак пункты чикләрендә автомобиль юллары чокырларын ямау (килешү буенча эш өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Нурлат муниципаль районы

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В.Белов